ПРОТОКОЛ
публичных слушаний

п.г.т. Богатые Сабы 12.12.2024 года

Присутствовали: 25 человек.

Председательствовал: заместитель Главы Сабинского муниципального района Республики Татарстан Р.Р.Закирзянов.

Секретарь: Рахимова Р.М.

Повестка дня:

1. О проекте бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов.

1.1. СЛУШАЛИ: Сунгатов Шамсун Акберович, председатель Финансово-бюджетной платы Сабинского муниципального райна, о проекте бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов.

Доклад прилагается к протоколу.

РЕШЕНИЕ (единогласно).

РЕШИЛИ:

1. Проект бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов принять за основу.

2. Проект бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов внести на рассмотрение заседания Совета Сабинского муниципального района Республики Татарстан.

Председатель: Р.Р.Закирзянов

Секретарь: Р.М.Рахимова

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПУБЛИЧНЫЕ СЛУШАНИЯ

# РЕШЕНИЕ

12.12.2024 года №1

О проекте бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов

Заслушав и обсудив доклад председателя Финансово-бюджетной палаты Сабинского муниципального района Сунгатова Ш.А., о проекте бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов и в соответсвии с Положением о публичных слушаниях в Сабинском муниципальном районе, граждане решили:

1. Проект бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов принять за основу.
2. Проект бюджета Сабинского муниципального района на 2025 год и плановый период 2026-2027 годов внести на рассмотрение заседания Совета Сабинского муниципального района Республики Татарстан.

Председатель
публичных слушаний: Р.Р.Закирзянов

**2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына**
**Саба муниципаль районы бюджеты проекты турында**
**ДОКЛАД**

Хөрмәтле гамави утырышка катнашучы иптәшләр!

Бюджет проектының беренче укылышыннан сон, 2025 елга бюджет проекты буенча фикер алышулар алып барылды.

Берләштерелгән район бюджетының керем өлешенең күләме буенча физик затлар керемено салым беренче урынны алып тора. 2025 елда бу сан өстәмә нормативларны исәпкә алып 550 млн. сум тәшкил итә.

Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым 2025 елда 64 млн. 386 мең сум җыйналыр дип фаразланды.

Патент нигезендә салым 2025 елда район бюджетына 5 млн. 827 мен сум керер дип көтелә.

Бердәм авыл хуҗалыгы салымын 2025 елда 3 млн. 797 мең сум җыйналыр дип фаразлана.

Тулысы белән җирле үзидарәләр бюджетында калачак физик затларның милкенә салым 2025 елда 9 млн. 315 мең сум итеп исәпләнде.

Җирле үзидарәләр бюджетының иң зур өлешен алып торучы җир салымы 2025 елда 21 млн. 400 мең сум җыйналыр дип көтелә.

Табигый байлыклар кулланган өчен түләүләр 313 мең сум җыйналыр дип фаразлана.

Дәүләт пошлинасы 3 млн. 182 мең сум булыр дип фаразлана.

2025 елда төп салым булмаган керемнәр берләштерелгән район бюджетына 21 млн. 837 мең сум тупланыр дип көтелә. Шуның эченнән тирә – як мөхитны пычратканга салым суммасының планы 3 млн 919 мең сум.

Җир биләмәләрен сатканнан 5 млн. 936 мең сум керер дип планлаштырылды.

Мөлкәтне арендага биргән өчен 1 млн. 171 мең сум, мөлкәтне саткан өчен 1 млн. сум тупланыр дип фаразланды.

Штрафлардан кергән керемнәр 508 мең сум булыр дип фаразлана.

Үзебездән җыелачак барлык керемнәр 2025 елда 702 млн. 214 мең сум булыр дип көтелә.

Республика бюджетыннан 2025 елда 1 млрд 526 млн. 477 мең сум акча килер дип исәпләнде.

Шулай итеп, 2025 елга керемнәр 2 млрд. 228 млн. 691 мең сум фаразланды.

Берләштерелгән район бюджетының чыгымнар өлеше түбәндәге үзгәрешләрне исәпкә алып эшләнелде:

- бюджет чыгымнарында шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указын тормышка ашыру кысаларында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең эш хакын арттыру өчен финанс чаралары планлаштырылуы;

- халык алдындагы йөкләмәләр, инфляциягә карап 1 нче гыйнвардан 4 процентка индексацияләнүе; -коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең 1 июльдән – 7,1

процентка, ашамлыклар, медикаментлар сатып алуга чыгымнарның 4 процентка индексацияләнүе көтелә.

Тулаем алганда, Саба муниципаль районының 2025 елга бюджет проекты һәм аның кушымталары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының бюджет кануннары җыелмасына нигезләнеп төзелде.

Алга таба Саба муниципаль районының киләсе елга берләштерелгән район бюджетының чыгым күрсәткечләренә тукталып китәм.

Гомуми дәүләт вәкаләтләрен башкарырга 121 млн. 477 мең сум бүленәчәк. Шуның эченнән резерв фондына 5 млн. 733 мең сум карала.

Беренчел хәрби учетны алып баруга чыгым – 3 млн. 751 мең сумны тәшкил итә.

2025 елда милли икътисад хэм торак – коммуналь хуҗалыкка барлыгы 289 млн. 475 мең сум каралды, шуның эченнән хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кешеләр һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан яклау чараларын уздыруны оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенция нигезендә 712 мең сум акча бирелер дип көтелә. Шул исәптән биотермик һәм үләт базларын тотуга – 347 мең сум, иясез хайваннарны аулау һәм яшәү мөхитен саклау өчен 365 мен сум каралган.

Муниципаль район чиклэрендэ муниципальара маршрутлар буенча пассажирлар йортуне оештыру очен 1 млн 352 мен сум фаразлана.

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлар түләүдән район бюджетына 22 млн. 157 мең сум акча керер дип көтелә. Бу сумма район башкарма комитеты аша авыл һәм шәһәр тибындагы бистә җирлекләрендә юл салу өчен тотылачак.

Урам утларына 14 млн. 35 мең сум; төзекләндерүгә 4 млн. 576 мең сум; су саклагычларын ремонтлау өчен 347 мең сум; паркларны тоту өчен 7 млн 597 мең сум; зиратларга 496 мең сум; яшелләндерү өчен 5 млн. 850 мең сум; мөлкәт салымына – 32 мең сум; йортлар ремонтларга – 2 млн. 253 мең сум; юллар эшлэу очен – 31 млн. 879 мең сум; авыл территорияләрен комплекслы үстерү чараларын гамәлгэ ашыруга субсидия – 3 млн. сум; найм килешүе нигезендә бирелүче торак төзелешенә субсидия күләме – 195 млн 767 мең сум бүленәчәк.

Бюджет чыгымнарының иң зур әһәмиятле тармагы - мәгариф өлкәсе. 2025 елга барлыгы бу өлкәгә 1 млрд 282 млн. 596 мең сум бүленде. Шуның эченнән террорчылыкка каршы көрәш кысаларында шәхси сак оешмалары өчен 2 млн.278 мең сум акча биреләчәк.

Яшьләр сәясәтенә 2025 елда 38 млн. 86 мең сум акча бүленә.

Икенче зур тармак – мәдәният өлкәсе, әлеге өлкәгә 200 млн. 276 мең сум карала.

Социаль өлкәгә 43 млн. 956 мең сум бүленәчәк.

Физкультура һәм спорт бүлегенә 238 млн. 983 мең сум фаразлана. Шулай ук террорчылыкка каршы көрәш кысаларында шәхси сак оешмалары өчен 1 млн.795 мең сум акча бүленәчәк.

Хөрмәтле гражданнар, хезмәт хакларын түләү, коммуналь чыгымнар, балаларны балалар бакчасында һәм мәктәптә бушка тукландыру, балаларны

мәктәпкә йөртү өчен транспорт чыгымнары, медикаментлар алу өчен акча алдан ук бюджетка салынган. Ә бюджет проектын анализлаганда, җирле үзидарә башлыклары тарафыннан күтәрелгән проблемаларны хәл итү, район бюджетына өстәмә керемнәр булган очракта гына башкару мөмкин булачак. Бюджет проектын әзерләү барышында ул сорауларны кабат тикшереп, хәл итү бурычы куелды. Җирле бюджетларны өстәмә керемнәр белән тулыландыру юнәлешендә эшне яхшырту 2025 елда актуаль булып кала.

Тулаем алганда, берләштерелгән район бюджетының керем һәм чыгым өлеше 2025 елда – 2 млрд. 228 млн. 691 мең сум булыр дип фаразлана. Район бюджетының икенче укылышына кадәр сездән эшлекле тәкъдимнәр көтәм. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

Докладчы,
Финанс-бюджет
палатасы рәисе

Ш.Ә.Сөнгатов